Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Маврина,
Ш.Ш. Яһудин
тарафыннан кертелә

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2010 елның 9 июнендәге 973-IV ДС номерлы карары редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 3 (II өлеш), № 10 (II өлеш), № 12 (V өлеш); 2006, № 1, № 10 (I өлеш); 2007, № 10, № 12 (IV өлеш); 2008, № 11 (IV өлеш); 2010, № 6 (III өлеш); 2011, № 3, № 12; 2013, № 5, № 12 ( II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2015, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2016, № 11; 2017, № 7, № 12; 2018, № 12; 2019, № 7 – 8; 2020, № 4; 2021, № 1 – 2, № 12; 2022, № 5 – 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә «иң югары вәкиллекле, закон чыгару» сүзләрен «вәкиллекле һәм бердәнбер закон чыгару» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 1 өлешендә:
а) 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 6 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 16 статьяда:
а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Дәүләт Советы Президиумы утырышларында киңәш бирү тавышы хокукы белән депутатлар, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиле яисә Татарстан Республикасы Рәисенең башка рәсми вәкиле, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе,

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе катнашырга хокуклы.»;

б) 6 өлештә «Дәүләт Советы Аппаратының» сүзләрен «Дәүләт Советының» сүзләренә алмаштырырга;

4) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 4 пунктта «Татарстан Республикасы» сүзләрен «закон нигезендә Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Регламент белән каралган очракларда башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

в) 6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 28 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Техник мөмкинлек булганда комитет утырышы Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында трансляцияләнә, комитет рәисе тарафыннан башка карар кабул ителмәгән булса.»;

6) 39 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт Советы беренче утырышка депутатларның билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе сайланган көннән 30 көннән дә соңга калмыйча чакырыла. Татарстан Республикасы Рәисе шушы срок эчендә Дәүләт Советын беренче утырышка үз инициативасы буенча чакыра ала.»;

7) 46 статьяның 1 өлешендә «радио аша» сүзләреннән соң «, шулай ук Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында» сүзләрен өстәргә;

8) 48 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Министрлар Кабинеты әгъзалары, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча

вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Советы тарафыннан рәсми вәкаләт тапшырылган Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары, муниципаль берәмлекләр башлыклары, җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары рәисләре, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе Дәүләт Советының барлык ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы. Башка затлар ябык утырышларда рәислек итүче чакыруы буенча гына катнашырга мөмкин.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Рәисе өчен Дәүләт Советының утырышлар залында махсус урын бирелә. Шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керүче затлар, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе вәкилләре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Советы тарафыннан рәсми вәкаләт тапшырылган Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары, муниципаль берәмлекләр башлыклары, җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары рәисләре, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе, Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентының вәкаләтле вәкилләре һәм башка чакырылган затлар өчен дә урыннар бирелә.»;

9) 55 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

10) 58 статьяның 1 өлешендәге беренче җөмләдә «комитетлары рәисләренә» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләренә» сүзләрен өстәргә;

11) 62 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиле яисә Татарстан Республикасы Рәисенең башка рәсми вәкиле, депутатлар, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Министрлар Кабинеты әгъзалары, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары рәисләре, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе ачык, шулай ук ябык парламент тыңлауларында катнашырга хокуклы.»;

12) 78 статьяның 2 өлешендә «катнашырга мөмкин» сүзләрен «катнаша» сүзенә алмаштырырга;

13) 83 статьяның 2 өлешендә «76 статьясында» сүзләрен «76 һәм $122^1$ статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

14) 84 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 85 статьяның 3 өлешендәге 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

16) 87 статьяда:

а) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

17) 88 статьяның 1 өлешендә «76 статьясы» сүзләрен «76 һәм $122^1$ статьялары» сүзләренә алмаштырырга;

18) 89 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

19) 91 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт Советында вәкаләтле вәкиле» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиле» сүзләренә алмаштырырга;

20) 92 статьяда:

а) 3 өлешнең 5 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «76 статьясы» сүзләрен «76 һәм $122^1$ статьялары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

21) 94 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

22) 95 статьяда:

а) 5 өлештә «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

23) 99 статьяда:

а) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм законнарына туры килү-килмәвенә» сүзләрен «Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвенә» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм законнарына каршы килә» сүзләрен «Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә,

федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «Дәүләт Советында Татарстан Республикасы Президентының Тулы вәкаләтле вәкиленә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиленә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «Дәүләт Советында Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтле вәкиле» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиле» сүзләренә алмаштырырга;

24) 101 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

25) 104 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

26) 106 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы законы кергән мизгелдән 14 календарь көн эчендә аны имзалый һәм халыкка җиткерә йә кире кага. Россия Федерациясе Президенты тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы законының конституциячеллеген тикшерү турында Россия Федерациясе Конституция Судына гарызнамә җибәрелгән очракта күрсәтелгән срок туктатып торыла.».

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы законы кире кагылган очракта, Татарстан Республикасы Рәисе аны, үзенең каршылыкларын белдереп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кабат карау өчен кире кайтара. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы законы кире кагылган очракта, әлеге закон депутатларның билгеләнгән санынннан

кимендә өчтән икесенең күпчелек тавышы белән элек кабул ителгән редакциясендә хупланырга мөмкин.»;

е) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Элек кабул ителгән редакциясендә хупланган Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кабат кире кагыла алмый һәм ул җиде календарь көн эчендә имзаланырга һәм халыкка җиткерелергә тиеш.»;

ж) 9 өлештә «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

з) 10 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

и) 11 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

к) 12 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

л) 13 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

27)110 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кире кагылган» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кире кагылган» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе һәм Дәүләт Советы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

28) 17 бүлекнең исемендә «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

29) 124 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**124 статья**

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 93 статьясы нигезендә Татарстан

Республикасы Рәисе Дәүләт Советы утырышында тантаналы шартларда үзенең ант иткән вакытыннан вәкаләтләрен башкаруга керешә.»;

30) 125 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфага керешү тантанасы үткәрелә торган Дәүләт Советы утырышы (алга таба әлеге статьяда – Дәүләт Советы утырышы) датасы, Татарстан Республикасының гамәлдәге Рәисе һәм Татарстан Республикасының яңа сайланган Рәисе фикерләрен искә алып, Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә.»;

в) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

31) 126 статьяда

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиле яисә Татарстан Республикасы Рәисенең башка рәсми вәкиле Татарстан Республикасы Рәисенә ышанычсызлык белдерү турында кертелгән тәкъдимгә бәйле рәвештә Дәүләт Советы утырышында белдерү белән чыгыш ясарга хокуклы.»;

д) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Рәисенә ышанычсызлык белдерү турындагы тәкъдим буенча фикер алышулар барышында депутатлар Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советындагы тулы вәкаләтле вәкиленә яисә Татарстан Республикасы Рәисенең башка рәсми вәкиленә сораулар бирә, әлеге мәсьәлә буенча үз фикерләрен җиткерә алалар.»;

е) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 8 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан

Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

32) 18 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 бүлек. **Татарстан Республикасы Премьер-министрын, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын билгеләп кую турындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен килештерү»;**

33) 127 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**127 статья**

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Премьер-министрын (алга таба – Премьер-министр), Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын (алга таба – Премьер-министр урынбасарларын) билгеләп кую турында Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимен килештерә.»;

34) 128 статьяда:

а) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Премьер-министр кандидатурасын килештерү турында карар, Дәүләт Советы тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә, яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Депутатларның билгеләнгән санынннан күпчелеге кандидатураны яклап тавыш бирсә, ул килештерелгән дип санала.»;

35) 129 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

36) 130 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**130 статья**

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителгән Премьер-министр кандидатурасын Дәүләт Советы хупламаса, Татарстан Республикасы Рәисе Дәүләт Советына башка кандидатура тәкъдим итә, аның буенча фикер алышу һәм тавыш бирү уздырыла. Татарстан Республикасы Рәисе башта тәкъдим ителгән кандидатураны кабат күрсәтә ала.»;

37) 131 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

38) 136 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

39) 137 статьяның 3 өлешендә ике җирдә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

40) 138 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**138 статья**

Дәүләт Советы Премьер-министрны һәм Премьер-министр урынбасарларын билгеләп кую турында Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен килештерү хакында карарлар кабул итә.»;

41) 140 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

42) 141 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

43) 21 бүлекнең исемендә «сайлау» сүзен «билгеләп кую» сүзенә алмаштырырга;

44) 144 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

45) 145 статьяда:

а) 2 өлештә «вәкил сайлау» сүзләрен «вәкилне билгеләп кую» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

46) 146 статьяда «сайланган» сүзен «билгеләп куелган» сүзләренә алмаштырырга;

47) $146^{1}$ статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

48) $146^2$ статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

49) 152 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга, «пайлар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

50) 170 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

51) 171 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

52) 172 статьяның 5 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

53) 31 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

54) 186 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат Дәүләт Советы утырышларында гарызнамә белән Татарстан Республикасы Рәисенә, Дәүләт Советы Рәисенә, Премьер-министрга, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә, Дәүләт Советы тарафыннан төзелә яисә сайлана торган башка органнарның вазыйфаи затларына (Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларыннан тыш), муниципаль берәмлекләр башлыкларына аларның компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

55) 187 статьяда:

а) 1 өлештә «министрлыклар» сүзеннән соң «, дәүләт комитетлары» сүзләрен өстәргә;

б) 5 өлешнең беренче җөмләсендә «затларга» сүзеннән соң «, дәүләт сере һәм законнар белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен истә тотып,» сүзләрен өстәргә;

56) түбәндәге эчтәлекле $187^1$ статья өстәргә:

**«$187^1$ статья**

1. Дәүләт Советы чакыруы буенча муниципаль берәмлек башлыгы яисә җирле үзидарәнең башка вазыйфаи заты Дәүләт Советы утырышларында тиешле муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат белән чыгыш ясый (алга таба – җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат) һәм, дәүләт сере һәм законнар белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен истә тотып, депутатларның сорауларына җавап бирә.

2. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат Дәүләт Советы Президиумы тәкъдиме белән тыңлана. Мондый карар Дәүләт Советы Президиумының үз инициативасы, шулай ук Дәүләт Советы депутатлары берләшмәләренең, комитетларының, комиссияләренең язмача мөрәҗәгатьләре нигезендә кабул ителергә мөмкин, алар үз мөрәҗәгатенә җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны тыңлау нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы карары проектын кушымта итеп беркетә ала.

3. Дәүләт Советы утырышына чакыру, депутатларны кызыксындыра торган сорауларны күрсәтеп, тиешле муниципаль берәмлек башлыгына утырыш үткәреләчәк көнгә кадәр кимендә биш көн кала җибәрелә.

4. Муниципаль берәмлек башлыгының яисә җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затының Дәүләт Советы утырышында катнашуы мөмкин булмаган очракта, муниципаль берәмлек башлыгы утырыш үткәреләчәк көнгә кадәр кимендә ике көн кала, килә алмауның сәбәпләрен күрсәтеп һәм, утырышка килеп, куелган сорауларга җавап бирәчәк вазыйфаи затны күрсәтеп, бу хакта Дәүләт Советына хәбәр итә. Бу очракта күрсәтелгән вазыйфаи затның утырышта чыгыш ясавы Дәүләт Советы белән килештерелә йә Дәүләт Советы утырышы көн тәртибеннән бу сорауны төшереп калдыру турында карар кабул ителә.

5. Дәүләт Советы утырышы көн тәртибеннән бу мәсьәлә төшереп калдырылган очракта җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат чираттагы утырыш көн тәртибенә кертелә.

6. Муниципаль берәмлек башлыгына яисә җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затына төп мәгълүмат белән чыгыш ясау өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә.

7. Депутатлар муниципаль берәмлек башлыгына яисә җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затына сораулар бирергә мөмкин. Сорау бирү вакыты бер минуттан артык, сорауга җавап бирү вакыты өч минуттан артык була алмый. Сораулар һәм җаваплар өчен гомуми вакыт 40 минуттан артык була алмый. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны тыңлау кысаларында фикер алышулар үткәрелми.

8. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны тыңлау нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы карары кабул ителергә мөмкин.»;

57) 189[1] статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә» сүзләренә алмаштырырга;

58) 32[1] бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32[1] бүлек **Татарстан Республикасы Рәисенең еллык юлламаларын һәм хисапларын карау»;**

59) 190[1] статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

б) өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

60) 190[2] статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Рәисе Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча, еллык хисап (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап), шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык җыелма доклад (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында доклад) тапшыра. Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында доклад Дәүләт Советы утырышында тыңлана.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:

«1[1]. «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисапка мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларның хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм күрсәтелгән оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча күрелә торган чаралар турында мәгълүмат, шулай ук мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм муниципаль берәмлекләр тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларның хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат кертелә.»;

в) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында доклад Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Дәүләт Советына, кагыйдә буларак, хисап елыннан соң килә торган елның 10 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында докладны карау датасы, Татарстан Республикасы Рәисе белән килештереп, Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында доклад, Дәүләт Советы утырышында аны караганчы, Дәүләт Советы комитетларына, депутат берләшмәләренә алдан карау өчен тапшырыла.»;

д) 4 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында докладны караганда Дәүләт Советы үз утырышында Татарстан

Республикасы Рәисен яисә аның йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Премьер-министрын тыңлый.»;

е) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында докладны тыңлау нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы карарлары кабул ителә.»;

61) $190^{2-1}$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

62) $190^{9}$ статьяның 3 өлешендә «бер көн алдан» сүзләрен «ике көн алдан» сүзләренә алмаштырырга;

63) 191 статьяда:

а) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

б) $2^{1}$ пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Премьер-министрны һәм Премьер-министр урынбасарларын билгеләп кую турында Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен килештерү турында;»;

д) 14 пунктта «сайлау» сүзен «билгеләп кую» сүзләренә алмаштырырга;

64) түбәндәге эчтәлекле $192^{1}$ статья өстәргә:

«**$192^{1}$ статья**

Дәүләт органнарының, вазыйфаи затларның, оешмаларның Татарстан Республикасы законнары, әлеге Регламент нигезендә Дәүләт Советы каравына кертелә торган хисаплары, докладлары, мәгълүматы Дәүләт Советының профильле комитетларында алдан карала.»;

65) $204^{4}$ статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт Советында вәкаләтле вәкиленә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советында тулы вәкаләтле вәкиленә» сүзләренә алмаштырырга;

66) 207 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проектына аңлатма

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты Дәүләт Советы Регламентын Татарстан Республикасы Конституциясенә (2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә), шулай ук «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында эшләнде.

Аерым алганда, проектта Татарстан Республикасы иң югары вазыйфаи затының атамасын Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясына туры китерү карала, Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфасына кандидатура турындагы тәкъдимен килештерү тәртибе, депутат гарызнамәсе белән мөрәҗәгать итү тәртибе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында, шул исәптән Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча, хисапны карау тәртибе төгәлләштерелә.

2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Дәүләт Советы утырышларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат тыңлау тәртибе билгеләнә.

Моннан тыш, Дәүләт Советы Регламентында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның комитетлары утырышларын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә турыдан-туры трансляцияләү тәҗрибәсе урнаштырыла. Дәүләт органнарының, вазыйфаи затларның, оешмаларның Татарстан Республикасы законнары, әлеге Регламент нигезендә Дәүләт Советы каравына кертелә торган хисаплары, докладлары, мәгълүматы Дәүләт Советының профильле комитетларында алдан каралу турындагы гомуми кагыйдә кертелә.